СОВЕТ ПЕЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

25.09.2017 | с. Печищи | № 23-107

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Печищи авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Печищи авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2017 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юллау белән риза булырсызмы:

- Су белән тәэмин итү системасын һәм су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм реконструкцияләү

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы А.С. Шамсутдинов